ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраля 2026г. № 1866

Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2024 елның 1 мартындагы 1324 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 25 февралендәге
1866 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Р.С. Хәмәдиев исемендәге «Тулпар» ат спорты мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| I. Транспорт чараларын саклау хезмәтләре | | | |
| 1. | Җиңел автомобиль | Ай/тәүлек | 1500,00/200,00 |
| 2. | Микроавтобус (3 м дан озын йөк Газеле) | Ай/тәүлек | 1700,00/250,00 |
| 3. | Трактор | Ай/тәүлек | 1800,00/250,00 |
| 4. | Йөк автомобиле ( 5,5 м дан озын йөк Газеле) | Ай/тәүлек | 2000,00/250,00 |
| 5. | Җиңел автомобиль тагылмасы (1,7 м дан 3,5 м га кадәр) | Ай/тәүлек | 1500,00/200,00 |
| 6. | Йөк автомобиле тагылмасы (3,5 м дан 8 м га кадәр) | Ай/тәүлек | 2000,00/250,00 |
| 7. | Мотоцикл (квадроцикл, самокатлар) | Ай/тәүлек | 1000,00/100,00 |
| 8. | Карда йөри торган транспорт чарасы | Ай/тәүлек | 1500,00/200,00 |
| II. Прокат хезмәтләре | | | |
| 9. | 14 яшькә кадәрге балаларга тимераяклар | кеше/1 сәгать | 110,00 |
| 10. | 14 яшьтән зуррак балаларга, зурларга тимераяклар | кеше/1 сәгать | 150,00 |
| 11. | Тимераякларны үткенләү | 1 хезмәт | 120,00 |
| 12. | Әйберләрне саклау | 1 сәгать | 50,00 |
| III. Чаралар оештыру һәм үткәрү хезмәтләре. Хайваннарны прокатка бирү | | | |
| 13. | Спорт атына атланып йөрергә өйрәнү буенча тренер белән индивидуаль дәресләр | 1 сәгать | 1500,00 |
| 14. | «Тулпар» АСМ – «Яр буе» паркы маршруты буенча тренер ярдәмендә:<br>- спорт атына<br>- понига атланып йөрү | 1 сәгать<br>1 сәгать | 850,00<br>600,00 |
| 15. | «Тулпар» АСМ территориясендә тренер ярдәмендә:<br>- спорт атына<br>- понига атланып йөрү | 1 маршрут/1 урын<br>1 маршрут/1 урын | 600,00<br>500,00 |
| 16. | Шәһәр чараларында тренер ярдәмендә:<br>- спорт атына<br>- понига атланып йөрү | 1 маршрут/1 урын<br>1 маршрут/1 урын | 550,00<br>450,00 |
| 17. | Шәһәр чараларында тренер ярдәмендә чаналарга, фаэтонга, каретага утырып йөрү | 1 маршрут/1 урын | 450,00 |
| 18. | Тренер ярдәмендә тантаналы рәвештә каретага утырып йөрү | 1 чара/1 сәгать | 3000,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 19. | Атны карап тоту хезмәте | Ай/тәүлек | 6500,00/300,00 |
| 20. | Ат черемәсе | 1 кг | 80,00 |
| 21. | Манежда дәресләр хезмәте | 1 сәгать | 600,00 |
| 22. | Атта фотосессия | 30 минут/1 сәгать | 2000,00/2500,00 |

*Автотранспорт чараларын саклау хезмәтләренә I, II төркем инвалидларга 50 %, хәрби хәрәкәтләр ветераннарына (тол калган хатыннарына), катнашучыларына 30% күләмендә ташлама бирелә, махсус хәрби операциядә катнашучыларга бушлай.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева